ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

07.12.2022 Иннополис шәһәре 98

«Муниципаль милек реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 июлендәге 52 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Иннополис шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегенең ачыклыгын, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль милек реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципал хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 июлендәге 52 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламентның 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацына үзгәреш кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Отформатировано

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гарызнамәче тарафыннан һәр запросның электрон формасын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең дөрес тутырылмаган электрон формасындагы кырын ачыклаганда мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-

uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитетының финанс бүлеге начальнигы Астраханцева Светлана Витальевнага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Хуззятов